БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
28 апрель 2021 ел

**КАРАР**
№49

**«2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2020 елның 16 декабрендәге 29 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елныц 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1.«2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2020 елның 16 декабрендәге 29 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2021 елга Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренец фаразлана торган гомуми күләмен 933002,45 мең сум итеп;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 938298,00 мец сум итеп;

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын 5295,55 мец сум итеп».

1.2. Карарның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны түбәндәгечә исәпкә алырга:

- әлеге карарның 17 нче кушымтасы нигезендә 2021 елда 622528,65 мең сум итеп;

- әлеге карарның 18 нче кушымтасы нигезендә 2022 елда 608628,41 мең сум һәм 2023 елда 593364,51 мең сум итеп.»

1.3. Карарныц 11 пунктын түбәндәге редакңиядә бәян итәргә:

«Балтач муниципаль районы Юллар фондыныц бюджет ассигнованиеләре күләмен 2021 елга 16000,00 мең сум, 2022 елга 16800,00 мең сум, 2023 елга

16900,00 мең сум итеп расларга һәм аларны тиешенчә 2021, 2022 һәм 2023 елларда Балтач муниципаль районының гомуми файдалану юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.».

1.4. Әлеге карарның 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче, 6 нчы, 7 нче кушымталары нигезендә «2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2020 елның 16 декабрендәге 29 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарының 1 нче, 3 нче, 5 нче, 7 нче, 9 нчы, 17 нче, 19 нчы кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин